ГЛАВА
БУРУНДУКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел Борындык авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Шүширмә торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 28 ноябренә 11 сәг 00 минутка Шүширмә авылы, Ямашев урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Шүширмә торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2025 елның 28 ноябренә 15 сәг 00 минутка Шүширмә авылы, Гагарин урамы янында урнашкан ООО “Туган як- Агро” административ зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Шүширмә торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Борындык авыл җирлеге Шүширмә авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны 2026 елда түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау(шул исәптән урам яктырткычлары, таймер, изоляцияләнгән чыбыклар сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгын чабу);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын, җиһазларны һәм ДЕПО бүлмәсен карап тоту);
- Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү?».

3. Әлеге карарны Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Борындык авыл җирлеге Башлыгы** **А.Р.Гайнетдинов**